**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 7 февраль № 65

г. Казань

Юлда халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге уртак кулланылыштагы автомобиль юлларына кушу буенча хезмәтләр бәясен, исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, «Татарстан Республикасында автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

юлда халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге уртак кулланылыштагы автомобиль юлларына кушу буенча хезмәтләр бәясе һәм исемлеге;

Юлда халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге уртак кулланылыштагы автомобиль юлларына кушу буенча чыгымнарны исәпләү тәртибе.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\65.docx